КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 23 март г.Казань № 265

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 12 сентябрь, 772 нче; 2019 ел, 18 март, 189 нчы; 2020 ел, 8 июль, 566 нчы; 2022 ел, 31 март, 298 нче; 2023 ел, 14 август, 975 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгълүматлаштыруны координацияләү буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2015 елның 14 ноябрендәге 1235 номерлы карары нигезендә мәгълүматлаштыруны координацияләү буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасы базасында Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып баруны тәэмин итәргә;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестры турындагы нигезләмәдә:

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестры – федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә төзелгән, мәгълүматлаштыруны координацияләү буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасын файдаланып алып барыла торган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгълүматлаштыруны координацияләү буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында»

2015 елның 14 ноябрендәге 1235 номерлы карары нигезендә эшли торган мәгълүмат системаларын исәпкә алу реестры;».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 февраль, 116 нчы; 2020 ел, 21 сентябрь, 848 нче; 2020 ел, 23 октябрь, 953 нче; 2021 ел, 16 август, 725 нче; 2023 ел, 20 февраль, 166 нчы; 2023 ел, 27 апрель, 532 нче; 2023 ел, 14 август, 975 нче; 2023 ел, 8 ноябрь, 1442 нче; 2024 ел, 29 июнь, 479 нчы; 2024 ел, 10 декабрь, 1128 нче; 2025 ел, 24 май, 353 нче; 2026 ел, 4 февраль, 67 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.2.19 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2.19. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгълүматлаштыруны координацияләү буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2015 елның 14 ноябрендәге 1235 номерлы карары нигезендә мәгълүматлаштыруны координацияләү буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасы базасында Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып баруны тәэмин итә;»;

3.3.4.4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.4.4. Учреждение, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә ведомство бүләкләрен һәм мактау билгеләрен гамәлгә куя һәм алар белән әлеге өлкәдә эшчәнлек башкаручы хезмәткәрләрне бүләкли;»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.4.30 пунктча өстәргә:

«3.3.4.30. «Россия Федерациясе халкы турында белешмәләр бирелгән бердәм федераль мәгълүмат регистры турында» 2020 елның 8 июнендәге 168-ФЗ номерлы Федераль законда каралган максатларда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе халкы турында белешмәләр бирелгән бердәм федераль мәгълүмат регистрыннан белешмәләр алуны гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин